**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘМБАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

5 апрель 2018 ел № 111

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Шәмбалыкчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депуталарның, сайлап куела торган вазыйфаи затларның, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында”**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018елның 28мартындагы 182 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Шәмбалыкчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба- муниципаль хезмәткәрләр) үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә торган хезмәт хакыннан (алга таба- хезмәт хакы), класслы чин өчен айлык өстәмә түләүдән, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хаеыга айлык өстәмә түләүдән, муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, айлык акчалата бүләкләүдән, аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкару өчен премияләрдән, еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән тора.

2. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре авыл җирлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларына караган кече төркем белгеченең 11163 сум тәшкил иткән вазыйфаи хезмәт хакы күләменнән чыгып исәпләнә.

3.Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентын 1 нче Кушымта нигезендә билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмен 2 нче Кушымта нигезендә билгеләргә.

5. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр түләнә:

1) муниципаль хезмәттә тиешле елларда эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына өстәмә түләү күләме:

| Муниципаль хезмәт стажы булганда | Өстәмә түләү күләме, |
| --- | --- |

| | процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан күбрәк | 20 |

2) классы чин өчен айлык өстәмә түләү күләме:

| Классы чин | Классы чин өчен өстәмә түләү күләме (вазыйфаи хезмәт хакына карата процентларда) |
|---|---|
| 1 | 2 |
| I классы гамәли муниципаль киңәшче | 7 |
| II классы гамәли муниципаль киңәшче | 5 |
| III классы гамәли муниципаль киңәшче | 3 |
| I классы муниципаль киңәшче | 7 |
| II классы муниципаль киңәшче | 5 |
| III классы муниципаль киңәшче | 3 |
| I классы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 7 |
| II классы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 5 |
| III классы муниципаль хезмәт киңәшчесе | 3 |
| I классы муниципаль хезмәт референты | 7 |
| II классы муниципаль хезмәт референты | 5 |
| III классы муниципаль хезмәт референты | 3 |
| I классы муниципаль хезмәт секретаре | 7 |
| II классы муниципаль хезмәт секретаре | 5 |
| III классы муниципаль хезмәт секретаре | 3 |

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары эн (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә ирешкән югары казанышлар, махсус эш режимы) өчен җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи хезмәт хакына билгеләнә торган айлык өстәмә түләү күләме:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 9 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 7 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 5 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 3 процентыннан;

муниципаль хезмәтнең кече вазыйфалары өчен – вазыйфаи хезмәт хакының 1 процентыннан;

4) айлык акчалата бүләкләү вазыйфаи хезмәт хакының 1 проценты күләмендә;

5)аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкару өчен (түләү тәртибе эш бирүче (эш кушучы) вәкиле тарафыннан муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфаи тәгълимнамәне үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып билгеләнә торган һәм хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә максималь күләм белән чикләнмәгән) премияләр;

6) матди ярдәм хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә билгеләнә;

7) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү 1,2 вазыйфаи хезмәт хакы күләмендә;

8) махсус эш режимы өчен айлык компенсацион түләүләр вазый фаи хезмәт хакының 2 проценты күләмендә бирелә.

Махсус эш режимы өчен айлык компенсацион түләүләр югары һәм төп муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштырып торган муниципаль хезмәткәргә, шулай ук чикләнмәгән эш көне режимында эшләүче башка муниципаль хезмәткәрләргә бирелә.

9) вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәләмәләр:

профильле галим дәрәҗәсендәге фәннәр кандидатына- вазыйфаи хезмәт хакының 1,5 проценты күләмендә,

профильле галим дәрәҗәсендәге фәннәр докторына вазыйфаи хезмәт хакының 2 проценты күләмендә түләнә.

6.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгына еллык түләнә торган ял биргәндә, бер тапкыр түләү елына айлык акчалата бүләкләү күләмендә бирелә.

7. Җирлек башлыгына акчалата бүләк елга унбер айлык акчалата бүләкләүнең норматив чикләрендә 11701 сум күләмендә түләнә.

8. Җирлек башлыгына муниципаль хезмәттә тиешле елларда эшләгәне өчен акчалата бүләкләүгә айлык өстәмә түләү түбәндәгечә билгеләнә:

| | |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5% |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10% |

| | |
|---|---|
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15% |
| 15 елдан күбрәк | 20% |

9. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи хезмәт хакларын өчен җибәрелә торган акча суммасыннан тыш, түләү өчен(1 елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи хезмәт хакыннан чыгып) түбәндәге чаралар күздә тотыла:

1) класслы чин өчен айлык өстәмә түләү- вазыйфаи хезмәт хакларының дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле елларда эшләгән өчен айлык өстәмә түләү- вазыйфаи хезмәт хакларының унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәттә махсус шартларда (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы) эшләгән өчен айлык өстәмәләр- вазыйфаи хезмәт хакларының биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) ) аеруча мөһим һәм катлаулы эшләр башкарган өчен премияләр- вазыйфаи хезмәт хакларының бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле ял алганда бер тапкыр бирелә торган түләү- вазыйфаи хезмәт хакларының ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалат бүләкләү- вазыйфаи хезмәт хакларының бер процентыннан артмаган күләмдә.

10.Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәре арттыру ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш дип бирелергә.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Интернет челтәренең телекоммуникация рәсми сайтында урнаштырырга.

12.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

13. Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче апреленнән көченә кергән хокукый мөнәсәбәтләргә тарала.

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**

**Шәмбалыкчы авылы җирлеге башлыгы-**
**Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл Советы**
**председателе Ф.Ф. Миннуллин**

2018 елның 5 апрелендә чыккан № 111
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Шәмбалыкчы авылы җирлеге Советы карарына
Кушымта № 1

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Шәмбалыкчы авылы җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладлы күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициенты**

| Вазифа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 1,00 |

2018 елның 5 апрелендә чыккан № 111
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Шәмбалыкчы авылы җирлеге Советы карарына
Кушымта № 2

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авылы җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме**

| Вазифа исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Шәмбалыкчы авылы җирлеге башлыгы | 11 701 |